РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 238

4 октября 2018 г.

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә 2018елның IV кварталына торак бинаның гомуми мәйданы бер квадрат метрына уртача базар бәясен раслау турында

Торак шартларын яхшырту буенча исәпкә куелган барлык категория гражданнарга социаль түләүләр күләмен билгеләү һәм аларга торак мәйданы алуга (төзүгә) әлеге социаль түләүләр федераль бюджет чараларыннан бүлеп бирелгән очракта, шулай ук торак шартларын яхшырту буенча исәпкә куелучы гражданнар өчен кулланылган башка хисапларны билгеләгәндә, Россия Федерациясе төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 12 сентябрендә гамәлгә кергән 572/пр номерлы «Россия Федерациясе субъектларында 2018 елның IV кварталына торак бинаның гомуми мәйданы бер квадрат метрына уртача базар бәясе күрсәткечләре турында»гы карарына нигезләнеп, карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә 2018 елның IV кварталына торак бинаның гомуми мәйданы бер квадрат метрына уртача базар бәясен 43 722 (кырык өч мең җиде йөз егерме ике) сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты торак сәясәте бүлеге башлыгы И.Н. Бәдретдиновка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкче урынбасары П.Н. Пугачев